# FIX

IT-компанияләр төркеме

# КОМПАНИЯ ТУРЫНДА

FIX компанияләре төркеме – электрон һәм кәрәзле коммерция проектларын ясау, интернет-трафик табу, югары басым астында эшли торган системалар эшләү, муниципаль һәм дәүләт секторын мәгълүматлаштыру эшендә махсуслаша торган халыкара IT-инкубатор.

- IT базарында 2006 елдан бирле эшли.
- Казанда, Мәскәүдә, Европада офислары бар.
- Иннополис резиденты.
- 400 артык хезмәткәр.
- 15 проект.

ИҢ ӘҺӘМИЯТЛЕ ПАРТНЕРЛАР:

- Google
- Mail.ru
- Alibaba Group
- Vkontakte
- МегаФон

# FIX КОМПАНИЯЛӘРЕ ТӨРКЕМЕ

- Компанияләр төркеменең эше эчке инкубатор прицибы буенча уза. Безнең һәр проект компания эчендә компанияләр төркемендәге башка проектлар белән багланышларда торып барлыкка килә һәм үсеш ала.
- Online-технологияләрне гадәти бизнеска юнәлтеп, без локаль компанияләргә үсәргә һәм үз төбәгеннән читкә чыгарга булышабыз. Глобаль проектлар өчен төбәк базарларында үз йогынтыңны җәелдерү мөмкинлеген бирә торган мәйданчыклар ясыйбыз.
- Бизнеста нетворкинг принципларына таянабыз: мәгълүмат алмашабыз, компанияләрнең тышкы һәм эчке ресурсларын кулланабыз, проектларны финанслау чыганакларын табабыз.
- Перспективалы стартапларга һәм белгечләргә ресурслар бирәбез һәм ярдәм күрсәтәбез.

# ПРОЕКТЛАР

# 01 Контент хезмәтләрен агрегацияләү платформасы

Кәрәзле контент, кыска номерлар белән эш итүне, тавыш бирүләр уздыруны тәэмин итә торган, кәрәзле коммерция функционалын үз эченә алган, кәрәзле элемтә операторлары өчен эшләнгән биллингалды платформасы.
Проект Россиядә, Азиядә, Африкада кәрәзле операторлар белән эшли.

Система контент белән эшләү һәм түләүләрне алдан эшкәртү өчен мәгълүмат җыю буенча бер секундка 6000 кадәр абонент гарызнамәсен эшкәртергә сәләтле. Шулай ук ул зур басымга каршы тора ала, мизгел эчендә тәэсир итәргә һәм ешлыклы үзгәрешләргә яраклашырга сәләтле булган сыгылмалы мантыйк системасына ия. Платформа BigData белән эшли һәм кәрәзле элемтә операторларына маркетинг стратегияләрен төзергә булыша.

# 02 EPN

Системаны эшләгәндә индивидуаль якын килү алымы һәм чишелешнең сыгылмалылыгы иң файдалы нәтиҗәләргә ирешү һәм Россиядә дә, чит илдә дә интернет-бизнес хуҗалары арасында киң танылу мөмкинлеген бирде. 2015 елда "Бөтендөнья шоппинг көне"ндә бер тәүлек эчендә безнең система аша AliExpress буенча 1 200 000 артык товар сатылды.

ePN — дөньядагы иң зур AliExpress интернет-кибетенең киңәйтелгән рәсми партнерлык программасы. Безнең тарафтан эшләп чыгарылган платформа дөньядагы иң зур AlibabaGroup партнерларының берсе булып тора, интернет-сайтларның, кәрәзле кушымталарның һәм социаль челтәрләрдәге бергәлекләрнең хуҗаларына трафикны тиз һәм җайлы рәвештә файдалану мөмкинлеген бирә. Безгә 300 000 артык веб-оста һәм  1000 000 артык файдаланучы ышана.

# 03 Кәрәзле һәм интернет-трафик

Безнең тарафтан VAS-хезмәтләр күрсәтү һәм кәрәзле интернеттан файдаланучыларны җәлеп итү буенча зур проектлар булдырылды. Катлаулы һәм күпфункцияле техника системалары эшләнде. Эшчәнлек географиясе Россияне, БДБ илләрен, Европаны, Азияне һәм Африканы колачлый.

2006 елда интернет-трафик җәлеп итү өлкәсендә эшчәнлек башлап, без тиз арада әлеге базарның иң яхшы командасына әйләнә алдык. Әлеге вакыт эчендә трафик җәлеп итү һәм ресурсларны Россиядә, БДБ һәм Европа илләрендәге зур компанияләргә күрсәтү буенча дистәләрчә проектны гамәлгә ашырдык. Без бер тәүлеккә ресурсларга суммар рәвештә 50 млн кадәр уникаль файдаланучының җәлеп ителүен тәэмин итәбез.

# 04 E-Commerce (электрон коммерция)

- Интернет-трафик базарында эшләп һәм үзгәрешсез рәвештә төрле түләү чишелешләренә дучар ителеп, безнең тарафтан берникадәр түләү системасы һәм банкинглар өчен техник функционал эшләнде. Проектның эше куркынычсызлык, челтәргә үтеп керүдән, аны җимерүдән югары дәрәҗәдә саклау, эшләүдән туктауга каршы торучанлык һәм технологик платформалар белән тәэмин ителгән.  Белешмәләрне югары халыкара стандартларына туры китереп яклауга махсус игътибар бирелә.

# 05 Ачык Шәһәр

"Ачык шәһәр" даими рәвештә үзенең географиясен киңәйтә. Хәзерге вакытта ул Татарстан Республикасының берничә шәһәрендә, Чечен Республикасында, Коми Республикасында һәм башка шәһәрләрдә дә эшли.

2011 елда Казанда "Ачык шәһәр" проекты эшләтеп җибәрелде, аның максаты муниципаль һәм инфраструктур хезмәтләр эшендәге үтәкүренмәлелекне тәэмин итүдән, шулай ук аларның эшендә нәтиҗәлелекне арттырудан гыйбарәт иде. Старт өчен илнең иң проблемалы өлкәсе – торак-коммуналь хуҗалыгы сайлап алынды. "Ачык шәһәр” – ул Россиядә беренче һәм шәһәр кешесен, башкарма комитет хезмәткәрен, идарәче компанияне, һәм инде, тагын бер әһәмиятлесе – подрядчы оешмада эшләрне иң актыккы башкаручыны бер мәйданчыкта берләштерә торган, ил өчен әлегә кадәр уникаль система булып тора. "Ачык шәһәр" системасы ярдәмендә илдә яшәүчеләрдән килгән 1.5 млн артык мөрәҗәгать уңышлы хәл ителде, идарәче компанияләр һәм подрядчы оешмалар эшендә нәтиҗәлелек дәрәҗәсе артты. Системада һәр йорт, аның элементлары, физик таушалуы турында проект базасында булган хәйран гына белешмәләр тупланган. Проект кысаларында конструктив элементларның һәм, тулаем алганда,

# 06 SEO –оптимальләштерү

- Компания 10 елдан артык төрле дәрәҗәле һәм тематикалы интернет-ресурсларны эшләп чыгару һәм алга таба күрсәтү өлкәсендә проектлар ясый. Безнең профиль – күп миллионлы кулланучысы булган глобаль проектлар. Без Россиядә һәм БДБ илләрендә иң зур "ВКонтакте" социаль челтәре һәм Россиядәге Ebay интернет-аукционы өчен эзләтү системасын оптимальләштердек. "ВКонтакте" заказы нигезендә мониторинг эше алып барыла: бренд белән паразит кертүче һәм кулланучыларның парольләрен урлаучы фишинг сайтларын күзәтеп торабыз.

# 07 SEO Conference

- 2010 елдан бирле уздырыла.
- Ел саен катнашучылар: Google, Mail.ru, VKontakte, Alibaba Group, WikiMart, Sape, Aviasales, Ingate.
- 2016 елда конференция Иннополис мәйданчыгында рекордлы санда катнашучы – Россиядән, Европа илләреннән һәм АКШтан 800 тирәсе кунакны туплады.
- 2015 елгы онлайн-трансляцияне 10 000 артык тамашачы карады.

Халыкара SEO Conference – SEO һәм Digital-маркетинг дөньясында иң масштаблы һәм абруйлы чараларның берсе булып тора.

# 08 технологияләр

Проектларны башкарганда безнең эшләп чыгаручылар үз эшендә нәтиҗәле технологияләрне һәм коралларны куллана.
Без берничә программа телендә проектлар эшлибез: Java, .NET, Python, Go, PHP. Эшләп чыгарыла торган чишелешләрнең архитектурасына, эшләп чыгару, тест уздыру һәм чишелешләрне җиткерү (delivery) процессларына махсус игътибар бирәбез.

Барлык проектларда да без югары басымнарга һәм зур күләмле белешмәләрне эшкәртүгә юлыгабыз. Безнең проектларда хәбәр чиратлары/messagebrokers (Kafka, RabbitMQ), NoSQL, белешмә базалары (Tarantool, Mongo DB) кулланыла, зур күләмле белешмәләрне эшкәртү өчен HBase һәм Hadoop, бүлгәләнгән файл саклагычлардан (HDFS), реляцияле белешмә базалары репликацияләреннән һәм шардингыннан (PostgreSQL, MySQL) файдаланабыз.

Чикләнгән ресурс шартларында зур белешмәләрне тиз арада эшкәртү өчен күпагымлы/concurrency, кичектерелгән исәпләмәләр актив кулланыла.

Системаларның куркынычсызлыгына һәм тотрыклы эшләвенә махсус игътибар бирелә. Эшләп чыгаруның барча этапларында QA-белгечләр кирәкле тестларны уздыра һәм сыйфатны тикшерә, автотестлар яза, эшләп чыгару командасы кодка даими ревью һәм эшләп чыгарыла торган система архитектурасына ревью

# Партнерлар

- Партнерлар ярдәме – масштаблы бизнесның нигезе ул. Бары тик уртак тырышлык нәтиҗәсендә генә эшли һәм табыш китерә торган проектны ясарга мөмкин.
- Шуңа күрә дә без нетворкинг: тәҗрибәләр һәм элемтәләр белән уртаклашу өчен ачык. Һәм безнең партнерлар бизнес буенча фикердәшләр булуы өстенә, уртак максатларга ия булган дусларыбызга да әйләнә.
- Без үзебезнең белән эшләүчеләрне, безгә базарда үсеш алырга һәм яңа позицияләрне яуларга булышучыларны бәялибез.

ПАРТНЕРЛАР:

- Google
- Mail.ru
- Alibaba Group
- Vkontakte
- МегаФон
- AliExpress

# ЭЛЕМТӘЛӘР


IT-ПАРКТАГЫ ОФИС
Казан ш., Петербург ур., 52,
3 кат, 310 офис
itpark@fix.ru

ҮЗӘК ОФИС
(843) 200 95 24
Казан ш., Тельман ур., 24
mail@fix.ru

ИННОПОЛИСТАГЫ ОФИС
Иннополис ш., А.С.Попов ис. технопарк,
3 кат, 321 офис
innopolis@fix.ru

Игътибарыгыз өчен рәхмәт!